ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 509 от «24» 12 2025 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 08 февралендәге 45 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Гражданнар оборонасы турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 23 июлендәге 240-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы көчләрен һәм чараларын билгеләнеше буенча куллануга даими әзерлектә тоту, хәрби конфликтлар вакытында яисә шушы конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы ситуацияләрдә гадәттән тыш хәлләр вакытында килеп чыга торган хәвеф-хәтәрләрдән халыкны яклауны тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 08 февралендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы көчләрен булдыру һәм аларны әзерлек хәлендә тоту турында» 45 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы көчләре турындагы Нигезләмәгә (алга таба- Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 3 пунктындагы 5 абзацында "хәрби конфликтлар булганда яисә шушы конфликтлар аркасында, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында" сүзләрен "хәвеф-хәтәрләр килеп чыгу нәтиҗәсендә"сүзләренә алмаштырырга.;

2. Әлеге карарны Интернет-телекоммуникация челтәрендә Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru/ рәсми сайтында һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2026 елның 20 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.М.Ефимов

0000015087